*Муниципаль тур*

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының татар төркемнәрендә белем алучы укучылар өчен татар теленнән олимпиада биремнәре**

***(2017/2018 нче уку елы)***

**VI сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл -68**

**I. Бирелгән сүзләрнең тамырын шартлы билге белән күрсәтегез. Тамырларының антонимнарын языгыз.**

Дөреслек, яхшылык, акыллы, канатсыз, шатлык, дымлы, көләргә, ялганла, аклык, яшьлек.

**II. Биремнәрне үтәгез.**

1. *Көчек үсә төшкәч, малай буш вакытларында, иртәдән кичкә кадәр аның белән уйнады. (Н. Каштанов)* җөмләсендә әйтелеше белән язылышы туры килмәгән сүзләрне билгеләгез.

2. *Шушы сүзләрдән соң киеренкелек йомшарды, Рафикъның күңеленә җылы йөгерде. (Н. Каштанов)* җөмләсендә ирен гармониясе күзәтелгән сүзне билгеләгез. Хикәя фигыльләрне табып, сораулары белән языгыз, заманнарын, зат-санын күрсәтегез.

3. *Үз атамны мин каты куллы булуы өчен сагынып искә төшерәм. (Г. Бәширов)* җөмләсеннән фразеологик әйтелмәләрне табып, мәгънәләрен аңлатыгыз.

4. *Фиркать, шатлыгын сиздермәскә тырышып, түтәлдәге, сары түшле шалканның яшел яфракларын учлап, йолкып та алды. (Н. Каштанов)* җөмләсендә кулланылган исемнәрнең килешләрен билгеләгез.

5. *Болытлар арасыннан ай күренде, ботаклар, чыршылар, наратлар өстендә карлар җемелдәде һәм карт усакның шома кәүсәсе көмештәй ялтырап*

*китте. (В. Бианки)* җөмләсеннән сыйфатларны язып алыгыз һәм артыклык дәрәҗәсенә куегыз.

6. *Дәү әниләре Зилә белән Индираны җитәкләде дә кызу гына өйләренә таба атлады. (Таңчулпан)* җөмләсенең баш кисәкләрен билгеләгез.

7. Алынма сүзләрнең синонимнарын языгыз: *сочинение, герой, километр, фотография, класс*.

**III. Яшәгән шәһәрегез (районыгыз яки авылыгыз) турында 10 сорау төзегез.**